**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ**

**"14" октябрь 2022 ел** **№ 59**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 28 апрелендәге 81 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (2018 елның 08 июнендәге 88 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 102 номерлы, 2019 елның 21 маендагы 125 номерлы, 2020 елның 22 сентябрендәге 9 номерлы карарлар редакциясендә)**

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр рәисләренең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль берәмлек башлыгының урынбасарының айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 октябрендәге 182 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган муниципаль хезмәтнең билгән вазыйфаларына туры китереп, 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмен исәпләү өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам..

Кама Тамагы муниципаль районының
Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Кече Салтык авыл җирлеге Советы рәисе А.Г.Җиһаншин